РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**Красновидовского сельского Поселения Камско-Устьинского муниципального района**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**Красновидово авыл**

**БАШЛЫГЫ**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

# КАРАР

**2019 елның 27 ноябре** **13 номерлы**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә Бортас авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. 2019 елның 10 декабрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Бортас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- авыл  эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Центральная урамы, 3 нче йорт, шулай ук ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 3 көн эчендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В. П. Оленин